**РАСЛЫЙМ**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, Мөфти
Камил хәзрәт Сәмигуллин
______________
«20» ___09___ 2016 ел

**РАСЛЫЙМ**
«Россия ислам институты» ректоры
Р.М. Мөхәммәтшин
______________
«20» ___09___ 2016 ел

# «Таян Аллага» әдәби конкурсының
# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**I. Конкурсның гомуми нигезләмәләре**

**1.1**. “Таян Аллага” әдәби конкурсы Россия Федерациясендә яшәүче татар яшьләре арасында яшь талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатында уздырыла.

Конкурсның бурычлары:

- сәләтле яшьләргә иҗади үсеш өчен шартлар булдыру;
- татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм ислам динен пропагандалау.

Оештыручылар:

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Россия ислам институты.

**1.2.** Вакыты һәм үткәрү тәртибе

Конкурс өч этапта үтә:

1 этап — әсәрләрне җыю (1 октябрь 2016 ел – 31 гыйнвар 2017 ел)

2 этап — әсәрләрне жюри тарафыннан бәяләү (1 февраль – 31 март 2017 ел).

3 этап — җиңүчеләрне бүләкләү (май 2017 ел).

**II. Конкурста катнашу шартлары**

**2.1.** Конкурста Россия Федерациясендә яшәүче 10 яшьтән 35 яшькә кадәрле һәрбер теләгән кеше катнаша ала.

**2.2.** Конкурс иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнмәүче яшьләр өчен үткәрелә, профессиональ язучыларның, шагыйрьләрнең, журналистларның әсәрләре һәм язмалары кабул ителми.

**2.3.** Конкурс дүрт номинациядә үтә:

- шигърият,
- чәчмә әсәрләр,
- драматургия,
- публицистик язмалар.